ГЛАВА ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.06.2026 г. Заинск № 109

**Кадастр номеры 16:19:070602:398 булган җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2026 елның 22 июнендәге 01-09-14439 номерлы хаты нигезендә

**карар бирәм**

1. Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Югары Шепкә авыл җирлеге, Имәнлебаш авылы, Ленин урамы адресы буенча урнашкан 16:19:070602:398 кадастр номерлы, 1 940 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча - Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының "Югары Шепкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең универсаль иҗтимагый-эшлекле зонасында" шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (ОД-У) гавами тыңлаулар билгеләргә.
2. Гавами тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:
1) Уразайкин П.С. – Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Башлыгы урынбасары;
2) Галеев Э.Э. – Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча);
3) Әгләмов Р.В. – «Җир төзелеше бюросы» ҖЧҖ директоры (килешү буенча);

4) Оборина Г.Ф. – Зәй муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе вазифаларын башкаручы (килешү буенча));
5) Камалиев Ф.Т. - Зәй муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча);
6) Кудряшов В.В. – Зәй муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча);
7) Усик О.В. – Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.
4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 23 июленнән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Муниципаль район башлыгы** **Р.Г. Кәримов**

О.В. Усик
9-90-47